ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28 01 2022 г. № 33

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына Түбән Кама шәһәре, Кама Аланы ш.т.п. һәм Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләре өлешен тапшыру турында кабул ителгән килешүләрне игътибарга алып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Әлеге карарга 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2022 елның 1 февраленнән 6 964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 59 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.Х. Муллин

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «28» 01
33 номерлы карарына
1 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районында 2022 елның 1 февраленнән
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге
бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү | 500,00 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 500,00 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 5964,68 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «28» 01
33 номерлы карарына
2 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районында 2022 елның 1 февраленнән
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге
бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне киендерү (кәфенләү) | 250,00 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү | 500,00 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 500,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 5714,68 |
| Барлыгы | 6964,68 |